**Тема: Тынычлыкның кадерен белик!**

**Катнашучылар**: 4 нче сыйныф укучылары, Бөек Ватан сугышы ветераны - Набиуллин Мансур абый, тыл ветераны- Закирова Мәфтуха апа.

**Максат:** Балаларга бүгенге тыныч тормышыбызның, бәхетле балачагыбызның бәясен төшенергә ярдәм итү;

Сугыш һәм тыл батырларына карата хөрмәт, Ватанны ярату хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Фотолар, плакатлар, сугыш күренешләрен чагылдырган рәсемнәр, шарлар, презентация.

**Дәреснең барышы.**

Тынычлык булсын

Килер көннәрдә,

Иминлек булсын

Бөтен җирдә дә!

Хәерле көн, кадерле укучылар, хөрмәтле кунаклар!

Һәр яңа көн тууга без бер-беребезгә шулай дип дәшәбез, тынычлык һәм иминлек телибез. Ә бит тыныч тормышта яшәмәгән, балачакларын рәхимсез сугыш урлаган кешеләр бихисап. Шуңа күрә безнең бүгенге тормышыбыз алар өчен җәннәткә тиңдер. Бу дәресне без бүгенге тормышыбызның, бәхетле балачагыбызның никадәрле кадерле икәне турында сөйләшүгә багышларбыз. Ә хәзер,әйдәгез, бераз тарихка күз салыйк.

Моннан нәкъ 71 ел элек дөньяда Гитлер исемен йөрткән бер адәм, бөтен кешене үзенә буйсндырырга теләп, сугыш башлаган. Ул яулап алган җирдә яшәүчеләр аңа буйсынырга, кол булып яшәргә тиеш булган . Ниятенең күпмедер өлеше трмышка да ашкан: Гитлер күп илләрне басып алган. Әлеге кара афәт 1941 нче елның матур җәендә безнең илебезгә дә үзенең канатларын җәйгән. Кыю ир-егетләребез Бөек Ватанны сакларга яуга киткәннәр.

"Герман көе" дигән җыр тыңлау.

Бөек Ватан сугышына безнең авылыбыздан 700 кеше киткән. Шуларның 456 сы әйләнеп кайта алмаган.Туган җирләре, газиз халкы өчен башларын салган бу батырларны онытырга хакыбыз юк безнең! Аларның исемнәре һәйкәлгә

язылган, ә якыннырының йөрәгенә уелган. Әйдәгез, алар истәлегенә бер минут тын торыйк!

Бер минут тынлык.

Сугыштан туган авылыбызга әйләнеп кайтучылырның сафлары елдан-ел сирәгәя бара. Бүгенге көнгә бер генә ветеран исән.  Ул Чишмә авылында гаиләсе белән яши. Мансур ага Нәбиуллин бүген бездә кунакта. Хәзер сүзне хөрмәтле ветераныбызга бирәбез.



**Мансур абый Нәбиуллин тормыш иптәше Гөлҗиһан апа белән.**

Рәхмәт, Мансур абый! Сезгә әле тагын бик күп еллар сау-сәламәт булып яшәргә язсын. Сезне хөрмәтләп Лиана һәм Сөмбел “Картаймагыз әле, ветераннар!” дигән шигырь сөйлиләр.

Күк йөзебезнең аяз булуында тыл батырларының да өлеше зур. Без бүген аларның да каһарман йөрәкләре, түземлелекләре, сабырлыклары, батырлыклары алдында баш иябез. Тол калган әбиләребез, ятим үскән сабыйлар язмышы кабатланмасын иде дип телибез.

Бүген бездә кунакта 5 бала анасы, тыл ветераны Мәфтуха апа Закирова. Хәзер сүзне сезгә бирәбез Мәфтуха апа.



Мәфтуха апа укучыларны сугыш чорындагы тормыш вакыйгалары белән таныштыра, балаларның сорауларына җаваплар бирә.

“Кояшлы ил” җыры башкарыла.

Бабаларыбыз яулап алган тыныч тормышыбыз безнең кебекләрнең һәммәсенә дә хас түгел әле. Тыныч тормышның кадерен белик.

Һәрчак безгә кояш көлеп карый,

Һәрчак зәңгәр безнең күгебез.

Без- яшь буын,

Иң бәхетле буын-

Дары исен белми күбебез.

Укучылар, дәресебезне тәмамлап, шуны әйтәсе килә: җиһанда сугышлар һичкайчан тынмаган. Сугышлар һәм канлы вакыйгалар алып килгән күз яшьләрен коярга насыйп  булмасын , күгебездә беркайчан да туплар

шартламасын, ятимнәрнең саны артмасын! Бүгенге сөйләшүдән гыйбрәт алыйк һәм тыныч тормышыбызның кадерен белергә өйрәник!

**Тынычлык сүзенә синквейн язу.**

“Һәрвакыт булсын кояш!” җыры башкарыла.

**Йомгаклау.** Очрашу табын янында дәвам итә.

Төзүче: Дәүләтбаева Рузилә Нуршаех кызы.